ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Пушкина, д.38, п.г.т.Уруссу, 423950

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Пушкин урамы, 38йорт, Урыссу ш.т.б., 423950

Тел.:(85593) 2-74-16, факс:2-62-20, e-mail:jutaza@tatar.ru, adm_jutaza@mail.ru, www: jutaza.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**7 ноябрь 2019 ел** **№ 807**

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль
районы Башкарма комитетының 2013 елның
16 сентябрендәге 512 номерлы карары белән
расланган мәктәпкәчә белем бирү буенча белем
бирү программасын гамәлгә ашырган белем бирү
учреждениеләренә йөрүче балалары булган
гражданнарга компенсацион түләүләр бирү
Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашырган белем бирү оешмаларына йөрүче балалары булган гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтү максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР КАБУЛ ИТӘ:

Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 16 сентябрендәге 512 санлы «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» гы карарына үзгәрешләр кертергә һәм аны «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмасында баланы карап торган һәм тәрбияләгән өчен ата-ана түләвенең максималь рөхсәт ителгән күләме» таблицасын яңа редакциядә бәян итәргә:

| Бер гаилә әгъзасына керемнең күләме | Ата-ана кертемен түләүгә гражданнар чыгымнарының максималь рөхсәт ителгән күләме (%) | | |
|---|---|---|---|
| | 1 нче балага | 2 нче балага | 3 нче балага |
| 10 000 сумга кадәр | 60 | 38 | 23 |
| 10 001 сумнан 15 000 сумга кадәр | 70 | 43 | 36 |
| 15 001 сумнан 20 000 сумга кадәр | 80 | 53 | 53 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 20 000 сумнан югары | 100 | 100 | 100 |
| Яшәү минимумыннан кимрәк (күп балалы гаилә өчен) | 0 | 0 | 0 |

2. Әлеге Карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «jutaza.tatarstan.ru» рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге Карар 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе А.Ә. Шафигуллин